СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

с. Шеланга № 5- -

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пунктына, Татарстан Республикасы, Шеланга авыл җирлеге Уставының 11 ст. ярашлы рәвештә,

Югары Ослан муниципаль районы

Шеланга авыл җирлеге Советы

Карар итте:

1. Шеланга авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрүнең уртак инициативасын тәкъдим итү:

"Сез 2015 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган һәр авыл җирлегендә яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

30 данә контейнер мәйданчыклары төзү, 150 данә контейнер сатып алу.

ЮК ӘЙЕ

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шеланга авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров